| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2025 п.г.т. Алексеевское № 212

**Башкарма комитетның 07.05.2024 ел, № 178 «Торак булмаган бинаны, корылманы һәм төзелмәне эксплуатацияләү өчен яраксыз (яраклы), авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча Алексеевск муниципаль районының ведомствоара комиссиясе турында» карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, торак булмаган бинаны һәм корылманы эксплуатацияләү өчен яраксыз (яраклы), авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тануның бердәм тәртибен куллану максатында һәм кадрлар алмашыну сәбәпле

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 07.05.2024 ел, №178 «Торак булмаган бинаны, корылманы һәм төзелмәне эксплуатацияләү өчен яраксыз (яраклы),авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча Алексеевск муниципаль районының ведомствоара комиссиясе турында» карарына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (Кушымта) бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е.Н. Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
23.05.2025 ел, № 212
карарына кушымта

**«Торак булмаган бинаны, корылманы һәм төзелмәне эксплуатацияләү өчен яраксыз (яраклы), авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тапу буенча Алексеевск муниципаль районының ведомствоара комиссиясе**
**Составы**

| | |
|---|---|
| Мельников Е.Н. | Комиссия рәисе, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Фомина Н.А. | Комиссия секретаре, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Әхмәтҗанов Р.Г. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Идел-Кама территориаль идарәсе башлыгы (килештерү буенча); |
| Шиһапов Р.Р. | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гражданнарны яклау идарәсе»муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе; |
| Хәмзина Е.А. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Дудкина Л.В. | ТТИ РДУПның 5 нче МРФ Алексеевск участогы башлыгы (килештерү буенча); |
| Павлова Э.Н. | Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе; |
| Фәсахова А.Р. | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килештерү буенча); |
| Тюкарев Ю.И. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килештерү буенча); |
| Хөснетдинов Р.Р. | Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча территориаль идарәсенең Чистай, Спас, Алексеевск һәм Яңа Чишмә районнарында территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килештерү буенча); |

________________ Алексеевск муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча).

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**